ГЛАВА КУРКАЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,,
п.ж.д.рзд. Куркачи, ул. Гагарина, 7

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КОРКАЧЫК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Коркачык тимер юл разъезды пос., Гагарин ур.,7

Тел./факс: +7(84365) 71-2-15, e-mail: Kurk.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**
**23 ноябрь 2021ел** | **№2**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегенең Коркачык тимер юл разъезды бистәсендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2021 елның 3 декабрендә 10 сәгать 00 минутта Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегенең Коркачык тимер юл разъезды бистәсендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2021 елның 3 декабрендә 13 сәгать 00 минутта Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегенең Коркачык тимер юл разъезды бистәсендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2021 елның 3 декабрендә 16 сәгать 00 минутта Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегенең Коркачык тимер юл разъезды бистәсендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Коркачык тимер юл разъезды бистәсендә яшәүчеләр Исемлеге халык җыенын үткәрү өчен территориаль билге буенча бүленгән:

а) беренче этап - Елга аръягы, Королев, Сәйдәшев, Урман, Тукай, Төзүчеләр урамнарында яшәүчеләр;

б) икенче этап - Горький, Тынычлык, Завод, Гагарин урамнарында яшәүчеләр;

в) өченче этап - Яшьләр, Хезмәт, Яр буе, Энергетиклар урамнарында яшәүчеләр;

5. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

2022 елда үзара салым кертүгә Биектау районының Коркачык авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500

сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме?:

1) контейнер мәйданчыкларын ремонтлау һәм коймалау
2) зиратны төзекләндерү
3) гидрантлар сатып алу һәм урнаштыру
4) Бөек Ватан сугышы һәйкәлен төзекләндерү
5) су бүлү һәм су белән тәэмин итү коеларын ремонтлау өчен.

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә

7. Карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Салихҗанов